Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Медведка торак пунктында гражданнар җыены карары

2025 елның 30 ноябре №2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Медведка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

««Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Медведка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Медведка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салымны 2 500,00 (Ике мең биш йөз) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Медведка авылы Дорожная ур. буенча грунт юлына вак таш салу; Медведка авылы Дорожная ур. буенча юлларны кардан чистарту).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек ур., 5 й., Медведкаав., Колхоз ур., 16Б; Медведкаав., Юл ур., 32; Михайловкаав., Үзәк ур., 4, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге башлыгы А.П.Бодряева